МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ**

**БОЕРЫК**

28.04.2018

**Казан ш.**

№ 263

Региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасы тарафыннан региональ йә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлының башка автомобиль юллары белән кисешү һәм региональ йә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлының башка автомобиль юлына килеп кушылу корылмаларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау максатларында язмача рөхсәт бирү тәртибен һәм мондый рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген раслау турында

“Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында” 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясындагы 3.2 өлеше нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасы тарафыннан региональ йә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлының башка автомобиль юллары белән кисешү һәм региональ йә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлының башка автомобиль юлына килеп кушылу корылмаларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау максатларында язмача рөхсәт бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) һәм мондый рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген расларга.

2. Тәртипнең үтәлешен ДКУ «Главтатдортранс» җитәкчесенә тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык 2018 елның 28 июненнән үз көченә керә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары А.В. Чукинга йөкләргә.

Министр в.б. А.Н. Усманов

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының 2018 елның
28 апрелендәге 263 номерлы
боерыгы белән расланды

**Региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасы тарафыннан региональ йә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлының башка автомобиль юллары белән кисешү һәм региональ йә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлының башка автомобиль юлына килеп кушылу корылмаларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау максатларында язмача рөхсәт бирү тәртибе һәм мондый рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеге**

1. Региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасы тарафыннан региональ йә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлының башка автомобиль юллары белән кисешү һәм региональ йә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлының башка автомобиль юлына килеп кушылу корылмаларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау максатларында язмача рөхсәт бирү тәртибе һәм мондый рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеге (алга таба – Тәртип) “Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 5.3 өлешенең 1 пункты һәм “Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында” 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясындагы 3.2 өлеше нигезендә эшләнде һәм региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлы (алга таба – региональ әһәмияттәге автомобиль юлы) хуҗасы тарафыннан региональ йә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлының башка автомобиль юллары белән кисешү (алга таба – кисешү урыны) һәм региональ йә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлының башка автомобиль юлына килеп кушылу (алга таба – кушылу урыны)

корылмаларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау максатларында язмача рөхсәт бирү турында гариза тапшыру тәртибен, шулай ук мондый рөхсәт бирү турындагы гаризага кушымта итеп тапшырыла торган документлар исемлеге билгели.

2. Автомобиль юлы хуҗасының язмача рөхсәтендә кисешү урынын һәм (яисә) кушылу урынын төзүче, реконструкцияләүче, капиталь ремонтлаучы һәм ремонтлаучы затлар мәҗбүри үтәргә тиешле техник таләпләр һәм шартлар күрсәтелергә тиеш.

3. Кисешү урынын һәм (яисә) кушылу урынын капиталь ремонтлау һәм ремонтлау эшләре башкарылганда, башка автомобиль юллары хуҗалары мондый эшләрне башкару тәртибен һәм мондый эшләрнең күләмен региональ әһәмияттәге автомобиль юллары хуҗалары белән килештерергә тиеш.

4. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән рөхсәт “Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршында Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе” дәүләт казна учреждениесенә җибәрелгән мондый рөхсәтне бирү турында гариза (алга таба – гариза) нигезендә региональ әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасы тарафыннан бирелә.

5. Гаризада түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) гариза адресатының исеме;

2) гариза бирүче турында белешмәләр:

физик зат, шул исәптән индивидуаль эшкуар өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта); физик затны индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәве турында белешмәләр; салым түләүченең идентификация номеры; яшәү урыны; телефоны (шәһәр кодын күрсәтеп), факс (булган очракта, шәһәр кодын күрсәтеп), электрон почта адресы (булган очракта);

юридик затлар өчен – оештыру-хокукый рәвешен күрсәтеп, тулы исеме; юридик затны дәүләт теркәве турында белешмәләр; салым түләүченең идентификация номеры; почта адресы; телефоны (шәһәр кодын күрсәтеп), факс (булган очракта, шәһәр кодын күрсәтеп), электрон почта адресы (булган очракта);

3) эшләрнең составы һәм аларны башкару срогы турында мәгълүматны күрсәтеп, рөхсәтне алуның максаты (кисешү урынын һәм (яисә) кушылу урынын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау);

4) җир кишәрлекләренең кадастр номерлары (мондый җир кишәрлекләре формалашкан һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган очракта);

5) региональ әһәмияттәге автомобиль юлына карата дислокацияне (километраж/пикетаж, уңнан/сулдан) күрсәтеп, кисешү урыны һәм (яисә) кушылу урыны планлаштырылган җир;

6. Гаризага түбәндәгеләр кушымта итеп бирелә:

1) Күчемсез милекнең бердәй дәүләт реестрыннан кисешү урыны һәм (яисә) кушылу урыны планлаштырыла торган җир кишәрлегенә карата өземтә яисә мондый документның гариза бирүче тарафыннан таныкланган күчермәсе;

2) җир кишәрлекләрендә региональ әһәмияттәге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса һәм юл буе полосасы чикләренең планлаштырыла торган кисешү һәм (яисә) кушылу схемасы, ул 1:1000 яисә 1:500 масштабында булырга һәм түбәндәгеләрне чагылдырырга тиеш:

кисешү урынын һәм (яисә) кушылу урынын;

региональ әһәмияттәге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса һәм юл буе полосасы чикләрен;

планлаштырыла торган объектны автомобиль юлына тоташтырып, янәшәдәге объектларны һәм инженерлык коммуникацияләрен;

3) автомобиль юлының буйга һәм аркылыга профиле;

4) эш проекты яисә проект документлары.

5) эшләрне үткәрү вакытына һәм алардан соң юл хәрәкәтен оештыру проекты;

6) территорияне планлаштыру документларын раслау турында белешмәләр (кисешү урынын һәм (яисә) кушылу урынын төзү, реконструкцияләү очрагында).

7. Гариза гариза бирүче тарафыннан имзалана, мөһер (булган очракта) белән таныклана.

8. Региональ әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасы гаризаны алганнан соң бер көн эчендә аны теркәргә тиеш.

9. Гариза бирүче мөрәҗәгате буенча региональ әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасы аңа гаризаны алу датасы һәм теркәү номеры турында белешмәләр бирергә тиеш.

10. Региональ әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасы түбәндәге очракларда рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итәргә мөмкин:

1) әлеге Тәртипнең 5 һәм 6 пунктларында күрсәтелгән белешмәләр һәм документлар тулы күләмдә тапшырылмаса;

2) әлеге Тәртип нигезендә региональ әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасы рөхсәт бирергә тиеш булмаса;

3) гаризада күрсәтелгән белешмәләр рөхсәт алу максатына туры килмәсә;

4) кисешү урынын һәм (яисә) кушылу урынын урнаштыру Таможня союзы комиссиясенең 2011 елның 18 октябрендәге 827 номерлы карары белән расланган “Автомобиль юлларының иминлеге” ТР ТС 014/2011 Таможня союзы Техник регламентында каралган таләпләргә, юл хәрәкәте иминлеге стандартлары һәм техник нормалары, экологик иминлек, автомобиль юлларын төзү һәм алардан файдалану таләпләренә һәм автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм ремонтлау өлкәсендә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә каршы килсә;

5) рөхсәт алу максатына комачаулый торган элек бирелгән рөхсәтләр булу.

11. Региональ әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасы әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән нигезләрдә рөхсәтне бирүдән баш тарткан очракта, региональ әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасы гаризаны теркәгән көннән алып утыз календарь көн эчендә  гариза бирүчегә рөхсәтне бирүдән баш тарту турында, баш тартуның сәбәбен күрсәтеп, дәлилләнгән язмача җавап җибәрә.

12. Региональ әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасы рөхсәтне бирү турында карар кабул иткән очракта, мондый рөхсәт региональ әһәмияттәге автомобиль

юлы хуҗасының гариза бирүчегә хаты рәвешендә рәсмиләштерелә һәм анда түбәндәгеләр булырга тиеш:

рөхсәт бирелә торган гариза бирүче турында белешмәләр;

рөхсәт алуның максаты (кисешү урынын һәм (яисә) кушылу урынын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау);

региональ әһәмияттәге автомобиль юлына карата дислокацияне (километраж/пикетаж, уңнан/сулдан) күрсәтеп, кисешү урыны һәм (яисә) кушылу урыны планлаштырылган җир;

кисешү урынын һәм (яисә) кушылу урынын урнаштыру планлаштырылган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары;

мәҗбүри үтәлергә тиешле техник таләпләр;

рөхсәтнең гамәлдә булу чоры (кисешү урынын һәм (яисә) кушылу урынын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау өчен җитәрлек вакытка, ләкин иң күбе ике елга);

региональ әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасының вазыйфаи заты имзасы.

13. Әлеге Тәртипнең 13 пункты нигезендә рәсмиләштерелгән Рөхсәт гаризаны теркәү датасыннан алып утыз календарь көн эчендә региональ әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасы тарафыннан гариза бирүчегә җибәрелә.

14. Юридик затны үзгәртеп корган, аның исеме яки урнашкан урыны үзгәргән, йә физик затның яки индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны үзгәргән очракта, региональ әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасы адресына, күрсәтелгән үзгәрешләрне раслаучы документларны кушымта итеп биреп, рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында мөрәҗәгать юллана. Региональ әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасы тарафыннан Рөхсәткә үзгәрешләр кертү мондый мөрәҗәгатьне теркәгән мизгелдән алып өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

15. Гариза бирүче карарга, региональ әһәмияттәге автомобиль юлы хуҗасы вазыйфаи затларының гамәлләренә яисә гамәл кылмауларына Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә шикаять белдерә ала.